| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 636-102/кс-2023

«Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм ташландык суларны (сәнәгый һәм явым-төшемнән агып җыелган суларын) агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 04.12.2020 №353-159/кс-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, техник суга (әйләнештәге су), су агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2024-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемenә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (әйләнештәге су), су агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) тарифлар билгеләү турында» 04.12.2020 №353-159/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №411-127/кс-2022 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Казаньоргсинтез» ГАҖ) өчен техник суга (әйләнештәге су), су агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
04.12.2020 № 353-159/кс-2020
карарына (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 636-102/кс-2023
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАЖ өчен техник суга (әйләнештәге су), су агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Чор | Техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык суларны агызуга тариф (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «Казаньоргсинтез» ГАЖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 0,98 | 10,98 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1,14 | 11,67 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1,08 | 11,40 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1,08 | 11,40 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1,30* | 12,08* |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1,30 | 12,08 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1,35 | 14,92 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1,35 | 14,59 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 1,62 | 14,59 |

* 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 411-127/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге